**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 апрель № 306

г. Казань

«Костер» республика балаларны сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Костер» республика балаларны сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе исемен «Костер» республика балаларны сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Республика үзәге) исеменә үзгәртү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 30 көн эчендә Республика үзәге уставын эшләргә һәм расларга.

3. Республика үзәге тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә әлеге карарны кабул итү белән бәйле Республика үзәге уставы расланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Костер» республика балаларны сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» балаларга өстәмә белем

бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе исемен әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\306.doc